| | | |
|---|---|---|
| ГОСУДАРСТВЕННЫЙ КОМИТЕТ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН ПО ТАРИФАМ | | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫНЫҢ ТАРИФЛАР БУЕНЧА ДӘҮЛӘТ КОМИТЕТЫ |

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

13.12.2023 г. Казань № 584-35/тко-2023

Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитетының аерым карарларын гамәлдән чыккан дип тану турында

«Әгерҗе муниципаль районы төзелеш идарәсе» муниципаль унитар предприятиесе өчен каты коммуналь калдыклар белән эш итү өлкәсендә хезмәт күрсәтү буенча җайга салынулы эшчәнлек төрен гамәлгә ашыруны туктатуга бәйле рәвештә, Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитеты идарәсе утырышының 13.12.2023 №57-ПР беркетмәсе нигезендә Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитеты КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитетының түбәндәге карарларын үз көчен югалткан дип танырга:

«Әгерҗе муниципаль районы төзелеш идарәсе» муниципаль унитар предприятиесе өчен каты коммуналь калдыкларны күмүгә 2021 – 2025 елларга чик дәрәҗә тарифлар билгеләү хакында» 17.12.2020 №547-7/тко-2020;

«Әгерҗе муниципаль районы төзелеш идарәсе» муниципаль унитар предприятиесе өчен каты коммуналь калдыкларны күмүгә Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитетының 17.12.2020 №547-7/тко-2020 карары белән расланган озак сроклы чик тарифларга 2022 ел өчен төзәтмәләр кертү хакында» 03.11.2021 №224-16/тко-2021.

2. Әлеге карар рәсми басылып чыккан көненнән соң 10 көн узгач үз көченә керә.

Рәис вазыйфаларын
вакытлыча башкаручы Л.В. Хәбибуллина